РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ ЯНУРУСОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
Село Янурусово, улица
Ленина, дом 43в, 423370
Телефон 4-10-19

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯНУРЫС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
Ленин урамы,43 в йорт, Янурыс
авылы, 423370 Телефон:
4-10-19

ОГРН 1031604000757 ИНН/КПП 1636001403/163601001 ОКАТО 92253884000

КАРАР

**РЕШЕНИЕ**

№ 16 19.09.2017 ел

Референдум уздыруны инициацияләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 июнендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22 ст., 56 ст. 1 ст. 1 нче статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының Республикасы Законының 20 ст. 1 п. нигезендә Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлеге советы карар итте.

1. Җирле референдум уздыруны түбәндәге сорау буенча тәкъдим итәргә:
"2018 елда Янурыс авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 250 сум күләмендә үзара салым кертүгә, I төркем инвалидлардан тыш, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

1 ) шартлар тудыру оешмалар өчен ял итү җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү, шул исәптән:
- мәдәни чаралар уздыру өчен музыка аппаратурасы сатып алу

- мәдәни чаралар өчен бүләкләр сатып алу;

2) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктыртуны, территорияне яшелләндерүне, урамнарның исемнәре һәм йортларның номерлары белән күрсәткечләр урнаштыруны, кече архитектура формаларын урнаштыру һәм карап тотуны да кертеп), шул исәптән:

- Каташ-Каран авылы балалар мәйданчыгын сатып алу;
- Янурыс һәм Каташ-Каран авыллары өчен светодиод лампочкалар сатып алу һәм урнаштыру;
- МТЗ-82.1 махсус техникасын тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машина йөртүченең хезмәте өчен түләү);
- җирлекнең торак пунктларында көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарны вакытлыча җыю урыннарын чистарту;

3) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту, шул исәптән:

- Янурыс авылы зиратын коймалау өчен төзелеш материаллары сатып алу.

4) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге, шул исәптән:

- Янурус авылы яр буе урамында вак таш ташу, вак таш җәю.

әйе юк

2.Әлеге карарны мәгълүмати стендларда һәм авыл җирлегенең рәсми сайтында кабул ителгән көннән алып 5 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көненнән үз көченә керә.

Янурыс авыл җирлеге
башлыгы А. А. Мөхәммәдиева